МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.05.2025 Казан ш. № 273-пр

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.12.2022 № 750-пр боерыгы белән расланган Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 29.12.2022 № 750-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.03.2024 № 125-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
19.05.2025 № 273-пр
боерыгын расларга

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 29.12.2022 № 750-пр боерыгы белән расланган Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.4.1 пунктның икенче абзацында «яки үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә Үтенеч язуы белән бергә түбәндәге документларны тапшыра (һәрберсе 1 данә):

1. Гариза бирүче – физик затның шәхесен раслаучы документ күчермәсе.

2. Ышанычнамә (үтенеч язуын гариза бирүченең вәкиле имзалаган очракта);

3. Җир кишәрлегенә хокук иясенең җир кишәрлеген бер категория җир составыннан башка категориягә күчерергә ризалыгы; әлеге җир кишәрлегенә сервитут урнаштыру турында килешү төзелгән зат җиргә хокук иясе булып торган очраклар искәрмә булып тора.

4. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге бер категория җир составыннан башка категориягә күчерү күзалланган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе күчермәсе (килешү булган һәм Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында чикләнгән хокуклар һәм аның аренда рәвешендә комачаулыгы булуы турында белешмә булмаган очракта);

5. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне җирле үзидарә вәкаләтле органы белән килештерү, соралган җир кишәрлегендә урнаштырылырга планлаштырылган федераль әһәмияттәге объектларның (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10 статьясының 1 кисәгендә күрсәтелгән өлкәләрдә), җирле әһәмияттәге объектларның, республика әһәмиятендәге объектларның расланган территориаль планлаштыру документларына туры килүе турында мәгълүмат, территорияне планлаштыру буенча документация (булса).

Килештерү вәкаләтле вазыйфаи зат имзалаган, сорала торган җир кишәрлегенең шартлы билгеләре, чикләре күрсәтеп тиешле тәртиптә расланган территориаль планлаштыруның документыннан күчерелгән кушымта белән тапшырыла.

Авыл хуҗалыгы җирлекләрен яки авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабреннән 172-ФЗ номерлы Федераль законының 7 статьясының 1 кисәгенең 4, 7, 9 пунктлары нигезендә күчерү очракларында килештерү андый объектларны урнаштыруның башка вариантлары булмауны раслаган документ белән тапшырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшыру нефть чыгару оешмаларының тиешле лицензияләр нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану өчен кирәкле скважиналарын һәм башка объектларын, шулай ук, федераль законнар белән мондый эшчәнлек тыелган территорияләрдән тыш, лицензияле территорияләр чикләрендә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә табигый битум ятмаларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатацияләүгә бәйле очракларда таләп ителми.

6. Җир кишәрлеген файдалы казылмалар табыштыру белән бәйле рәвештә күчергәндә үтенеч язуына нотариаль яисә җитәкче яки аның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы белән һәм җир асты байлыкларын файдаланучы оешманың мөһере (булса) белән расланган түбәндәге күчермәләр теркәлә:

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия;

лицензиягә (булган очракта) өстәмә килешү (өстәмәләр);

җир асты файдаланыласы урынның чикләре план-картография материалында билгеләнгән горноотвод акты (таяну, параметрик, структуралы, эзләнүле, бияләү һәм тикшеренү скважиналарын урнаштырудан башка).

7. Җир асты байлыкларын чыгару белән бәйле очракларда тиешле тәртиптә расланган җирләрне рекультивацияләү проекты, яки линияле объектлар төзелеше вакытында бирелә торган авыл хуҗалыгы җирләре өлешен рекультивацияләү проекты.

8. Җир кишәрлеген гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары янындагы полосалар чигеннән күчергән очракта – килешүләр:

Россия Федерациясе законнары нигезендә хокукый яктан автомобиль юлларын биләп торган дәүләт хакимияте, җирле администрациянең башкарма органы, физик яки юридик затлар;

«Юл хәрәкәте иминлеге» ресмпублика дәүләт учреждениесе (җир кишәрлеге Татарстан Республикасының гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары янындагы полосада  урнашкан очракта);

9. Физик затлар, шул исәптән, юридик затларның вәкилләре һәм хосусый эшмәкәрләр шәхесләрен раслаучы документ күчермәләре һәм персональ мәгълүматны эшкәртүгә ризалык тапшыралар.

Үтенеч язуына теркәлгән документлар нотариуста яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланмаган булса, күчермәләре тапшырылган төп нөсхә күрсәтелә һәм Министрлык Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге белгече (алга таба – Бүлек) тарафыннан раслана.»;

2.6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алына торган документлар:

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

1. Шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә яки ТР буенча Федераль салым идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ) 30 көннән дә элегрәк бирелмәгән шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу бите.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ) 30 көннән дә элегрәк бирелмәгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите.

3. Җир кишәрлеге турында яки ЕГРНда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү ниятләнгән җир кишәрлегенә соралган мәгълүматлар булмавы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН), “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы” дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан (алга таба – ТР буенча ФКП).»;

3 бүлектә:

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече үтенеч язуы Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.7.2 пунктта «“ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә

күчерү турында үтенеч язуы үтү битен” тутыра (әлеге Регламентка 2 нче кушымта),» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле соралган документлар исемлеге:

1. ЕГРИПтан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә яки ТР буенча Федераль салым идарәсеннән 30 көннән дә иртәрәк алынмаган шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу бите. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана.

2. ЕГРЮЛдан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки ТР буенча ФСХИдан 30 көннән дә иртәрәк алынмаган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите.

3. ТР буенча ФКПдан үтенеч язуы тапшырылганга кадәр алты айдан да элегрәк алынмаган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү ниятләнгән җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар регистрацияләнгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.»;

Административ регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
25.10.2006 № 523 карары белән
расланган)

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгына

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешеннән
башка категориягә күчерү турында
үтенеч язуы

________________________________________________________________
(гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме яки юридик затның атамасы)
гомуми җир кишәрлеген мәйданы ___________________________________
гектар булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән
кадастр номеры ____________________________________________,
_____________________________________________ хокукында
(хокук атамасы)
______________________________________________________________
(җирдән файдаланучының атамасы)
Татарстан Республикасының _______________________ районы территориясендә
(муниципаль район атамасы)
______________________________________________________
категориясенә
(җир кишәрелеген күчерү соралган категория атала)
__________________________________________________________

____________________________________________________ күчерүне сорыйм.
(максатчан билгеләнеше)
Күчерү нигезе:
1) ___________________________________________расланган
(карар реквизитлары)
территорияне планлаштыруның расланган документына туры килә;
2) объектларны урнаштыруның башка вариантлары юк.
______________________________________
муниципаль берәмлекнең башкарма органы документы реквизитлары (җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабреннән 172-ФЗ номерлы Федераль законының 7 статьясының 1 кисәгенең 4, 7, 9 пунктлары нигезендә күчерү очракларында күрсәтелә)

| | |
|---|---|
| Гариза бирүченең почта адресы | |
| | |
| Элемтә өчен телефон | |

Әлеге үтенеч язуына исемлек буенча документлар теркәлә.
Гариза бирүче(ләр)нең, ышанычнамә буенча вәкил(ләр)нең имзасы.
«__»__________ №______
________________________________________________________/_______________
(гариза бирүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисе исеме) (имза)

М.П. (булса)

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуына кушымта

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуына беркетелгән документлар исемлеге

| Документ атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

_______________________________ ___________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

_______________________________ ___________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Бөтен документлар 1 данәдә тапшырыла.»

Административ регламентка 2 нче кушымтаны көчен югалткан дип танырга;

кушымтаның(белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасында «Җир ресурслары идарәсе башлыгы» юлын төшереп калдырырга.